| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.02.2020** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 187** |

Зеленодольск шәһәре территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен махсус мәйданчыкны билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 13 ст. 5 ч. 3 п. һәм 8 ст., «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге мәйданчыкны билгеләргә:
   - этләр йөртү өчен Чкалов урамындагы 2а нче йорт янында «Шәһәр күле» паркындагы мәйданчык.
2. Әлеге карарны ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.З. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин